**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631д.Дятлово ,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАМА КОМИТЕТЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

2025 елның «30» гыйнвары 1 номер

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында»**

Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү ү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында" 2025елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә, карар бирәм**:**

1. 2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1, 2 кушымталар нигезендә, 9165,37 сум күләмендә дип билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. 2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Башкарма комитетының «2025 елга җирләү буенча гарантияле хезмәтләр күрсәтү исемлегенә тарифларны раслау турында» 2024 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карары үз көчен югалтуын таныйрга.
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **С.М.Гуцу**

Татарстан Республикасы
Рождествено авыл җирлеге Башкарма комитетының
2025 елның 30 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
1 кушымта

**2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтү исемлеге бәяләре.**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җиткерү | 5398,28 |
| 3. Зиратка мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) илтү | 1450,31 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү)ү) | 2316,78 |
| БАРЛЫГЫ | **9165,37** |

Татарстан Республикасы
Рождествено авыл җирлеге Башкарма комитетының
2025 елның 30 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 кушымта

**2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Рождествено авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтү исемлеге бәяләре**

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләр бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 775,60 |
| 3. Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җиткерү | 4622,68 |
| 4. Зиратка мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) илтү | 1450,31 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2316,78 |
| БАРЛЫГЫ | **9165,37** |